**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Олыяз авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2025 елның 30 октябре** **№ 4**

**Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2025 елның 28 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 1 этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Олыяз авылы, Яңа урам, 11 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2.2025 елның 28 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2 этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Олыяз авылы, Яңа урам, 11 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге Олыяз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау

урамнарны яктыртуны ясау;

су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;

янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;

һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү,

ремонтлау, карап тоту;

тротуарларны төзү, ремонтлау;

тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру;

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау;

ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү;

каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерүме?

«РИЗА» «КАРШЫ».

4.Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлергә.

5. Гражданнар җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Олыяз авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Олыяз авыл җирлеге башлыгы Р. Ф. Маликов